
МАОУ СОШ №4

# Наше Время!
# Безнең Вакыт!


СПЕЦВЫПУСК ДЕКАБРЬ






## Якынлашып килүче Яңа ел белән сезне!



Яңа ел ул – үргә баскыч,
Бәхетеңә тәрәзә.
Яңа шатлык, яңа ачыш,
Яңа абруй, дәрәҗә.



Яңа ел ул – күк гөмбәзендә
Ил йөген индә йөртүче.
Җемелдәүче энҗеләр,
Ару белмәс кешеләр.



**Кыш бабай.** **Факил Сафин.**

Кыш бабаем күптән килеп
Яудырса да ак карлар,
Үзен күргәнем юк иде
Бүгенгедәй якыннан.

Баргач чыршы бәйрәменә
Минем яныма килде.
Аркаларымнан сөеп,
Миңа күчтәнәч бирде.



Яңа яуган кар өстеннән
Чаптырып пар ат килә,
Чөнки быел аның елы,
Искесе инде китә.
Әйдә, атым, хуш киләсең,
Яңа елга аяк бас.
Күчтәнәчләреңне төяп,
Капчыкларыңны да ас.




Әгъләмова Эльвина

Әниемнең куллары
Кояштан да җылырак,
Әниемнең күзләрендә
Ярату һәм сабырлык.
Әнием һәрвакытта
Янымда гына була,
Кайгырсам да, мин көлсәм дә
Яратып саклап тора.




Хәмәдишин Булат 3Б

# САФИН ФАКИЛ

**Язучы Факил Миңнемөхәммәт улы Сафин (әдәби тәхәллүсе – Факил Әмәк) 1954 елның 2 гыйнварында Татарстанның Мөслим районы Әмәкәй авылында туа.**

**Факил кечкенәдән әдәбият-сәнгать белән кызыксынып үсә. Бишенче сыйныфта укыганда, шигырьләр, дөресрәге, эпиграммаларга тартым тезмәләр яза башлый. Беренче шигырьләре, урта мәктәпне тәмамлагач, район газетасында басылып чыга. Уку елларында, барлык яшьтәшләре кебек үк, җәйге-көзге чорда колхозда эшли: йөкче, көтүче, комбайнчы ярдәмчесе һ.б. хезмәтләр башкара. Ул Күбәк урта мәктәбен тәмамлап, Минзәләдә шоферлыкка укып кайткач, колхозда механизатор булып та эшләп ала. Ф.Сафин 1972–1974 елларда Ерак Көнчыгышта, Кытай чигендә гаскәри хезмәттә була. Армиядән соң районның «Михайловка» совхозында – комсомол оешмасы секретаре, бераз соңрак Иске Карамалы авылында Мәдәният йорты директоры булып эшли. Ләкин югары белем алу теләге озакламый аны Казанга алып килә. Ул, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлап, шактый гомерен мәгариф эшенә багышлый: әүвәл Мөслим төбәгендәге Октябрь авылында, аннары туган авылы Әмәкәйдә, Татар Бүләре урта мәктәпләрендә татар әдәбияты, тарих укытучысы һәм мәктәп директоры (Октябрь, Татар Бүләре авылларында) хезмәтендә була.**

**1984 елдан Факил Сафин гаиләсе белән Чаллы шәһәренә килеп төпләнә. 1988 елга кадәр ул КамАЗның автомобильләр җыю заводында, баш конвейерда, слесарь-җыючы, бригадир, мастер булып эшли.**

**1988 елда Чаллы шәһәренең Автозавод районы мәгариф бүлеге Ф.Сафинны янәдән укытучы эшенә чакырып ала. Ул шәһәрнең 24 нче, 18 нче мәктәпләрендә тарих укыта, шул җөмләдән шәһәр мәктәпләрендә беренче буларак рус телле балаларга «Татар халкының тарихы, әдәбияты, мәдәнияте» дигән яңа предметтан дәресләр бирә башлый.**

**Узган гасырның туксанынчы еллары башында Ф.Сафин Чаллыда «Таң йолдызы» исемле газетада – баш мөхәррир урынбасары, КамАЗ радиосының татарча тапшырулар редакциясендә һәм 1991 елның августыннан яңа оешкан «Аргамак» журналының проза һәм шигърият бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1993 елның көзеннән әлеге журналның сәркәтибе итеп билгеләнә. Шушы чорда әүвәл Чаллы көндәлек матбугатында, соңга таба Казандагы газета-журнал битләрендә «Факил Әмәк» тәхәллүсе белән аның күп кенә шигырьләре һәм хикәяләре дөнья күрә. 1992 елда исә «КамАЗ» нәшриятында хикәяләре һәм бер повесте тупланган «Соңгы көз» исемле проза китабы, ә тагын ике елдан Казанда «Тузганак чәчәге» дигән шигырьләр җыентыгы басылып чыга.**




## ТӨП БАСМА КИТАПЛАРЫ

**Соңгы көз: повесть, хикәяләр. – Чаллы: КамАЗ, 1992. – 112 б. – 7000 д.**
**Тузганак чәчәге: шигырьләр. – Казан: Идел-Пресс, 1994. – 96 б. – 10000 д.**
**Гөлҗиһан: повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 288 б. – 3000 д.**
**Биек тауның башларында: роман. – Казан: Идел-Пресс, 1998. – 240 б. –**
**Сәфәр: шигырьләр. – Казан: Идел-Пресс, 2002. – 168 б. – 1000 д.**
**Саташып аткан таң: роман-трилогия / кереш сүз авт. Н.Гамбәр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 527 б. – 5000 д.**
**Ләлә белән Арслан: балалар өчен хикәяләр, әкиятләр. – Казан: Мәгариф, 2005.**
**Шәүлә: роман, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 288 б. – 3000**

**1995 елның гыйнварыннан Факил Сафин шәһәр мәгариф идарәсе тәкъдиме белән Чаллы педагогия көллиятенә укыту эшенә күчә. Укыту-тәрбия өлкәсендә яңа технологияләр, яңа методик алымнар куллану ихтыяҗыннан шәһәр мәгарифе җитәкчеләрен Чаллыда фәнни-методик журнал чыгару фикеренә этәрә. Яңа журналны оештыру Ф.Сафинга йөкләнеп, 1996 елның октябрь аеннан «Фән һәм мәктәп» дигән журнал чыга башлый. 2001 ел башында Чаллыда яңа иҗтимагый әдәби-нәфис журнал оештыру турында фикер тугач, шәһәр хакимияте һәм Татарстан Язучылар берлеге идарәсе бу эшне башкарып чыгу мәшәкатьләрен янә Ф.Сафин өстенә йөкли. Нәтиҗәдә 2001 елның августыннан «Мәйдан. Чаллы» дип исемләнгән айлык журнал чыга башлый. Журналның баш мөхәррире итеп Факил Сафин билгеләнә. 2005 елның июненә кадәр шул хезмәтендә була, ә Татарстан язучыларының XV корылтаенда ( 2005, май ) ул Берлек идарәсенә әгъза һәм Берлек идарәсе рәисенең урынбасары итеп сайлап куела, 2006 елдан Рухи мирасны өйрәнү төбәк фәнни-методик үзәген җитәкли.**

**Ф.Сафин – әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе туплап килгән, беренче әсәрләре белән үк укучыларның игътибарын яулап алган үзенчәлекле прозаикларның берсе. Ул – «Соңгы көз» (1989), «Гөлҗиһан» (1994) повестьлары, «Биек тауның башларында» романы (1999), «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе (2002), «Шәүлә» романы, «Галәм күзе» китабы (2011), «Җыр-гомер ул» җырлар китабы (2013), күпсанлы хикәяләр, публицистик язмалар, шигырьләр, эпиграммалар, пародияләр һәм Кадыйр Сибгатуллин, Рәшит Бәшәр, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов һәм башка язучыларның иҗатларына багышланган фәнни-тәнкыйди мәкаләләр авторы.**

**Ф.Сафинның җыр-музыка өлкәсендәге эшчәнлеге дә игътибарга лаеклы. Шәһәр үзешчән композиторлары арасында ул, беренчеләрдән булып, Казанда Татарстан Президенты аппараты һәм «Җыен» фонды үткәргән балалар җырлары конкурсында, аннары Чаллыда үзе оештырышкан «Тургай» җыр фестивалендә катнашып, җиңү яулаган лауреатларның берсе була. Ул шулай ук Чаллыда балалар иҗат түгәрәкләре, балалар өчен «Көмеш кыңгырау» исемле газета оештыру эшен дә башлап йөри. Ф.Сафин балалар язучысы буларак та билгеле. Аның балалар психологиясен тирәнтен тоеп язган әсәрләре «Сабантуй», «Көмеш кыңгырау» газеталарында, «Салават күпере», «Ялкын», «Мәйдан» журналларында даими басыла килә. 1994 елда курчак театрлары өчен Ю.Чеповецкидан тәрҗемә иткән «Тычкангали һәм Мыраубәк» спектаклен яшь тамашачылар яратып кабул итәләр. Үз вакытында Чаллы Язучылар оешмасы рәисе урынбасары, «Ләйсән» әдәби-иҗат берләшмәсе җитәкчесе (1999–2002) буларак та Ф.Сафин яшь әдәби көчләрне тәрбияләү эшенә үзеннән зур өлеш кертә. Ул – Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе (1999), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (2004), филология фәннәре кандидаты (2007). Ф.Сафин – 1996 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. “Тәрҗемә Олимпы” һәм “Кояшлы иҗаты өчен” халык ара бүләкләр иясе .**

## ИҖАТЫ ТУРЫНДА

**42 ел**


**Әгъләмов М. Шигъри әнкә баласыдыр // Шәһри Казан. – 1993. – 10 июнь.**
**Вәлиев М. Яңа исемнәр, яңа әсәрләр // Казан утлары. – 1994. – № 1. –**
**Мөслимова Ф. Уч тулы талант // Сабантуй. – 1994. – 2 июнь.**
**Сафуанов И. Үз тавышы, үз моңы // Шәһри Казан. – 1995. – 18 март.**
**Сибат Р. Кеше оясы кайда? // Шәһри Казан. – 1995. – 28 июнь.**
**Җамалетдинова Ф. Өлешемне өстәү тиеш // Таң йолдызы. – 1997. – 29**
**Әшрәфҗанов Х. Гөлҗиһан ядкәре // Мәдәни җомга. – 1998. – 18 дек.**
**Бәйрәмова Г. Шәфкать һәм вәхшәт // Казан утлары. – 1999. – № 5. – 181–**
**Заһидуллина Д. Кызгана белгән игелек кыла // Ватаным Татарстан. –**
**Бәшәр Р. Кояшлы иҗат // Шәһри Чаллы. – 2003. – 31 дек.**
**Галиева Г. Мәйдан тоткан егетләрдә өмет // Мәдәни җомга. – 2004. – 23**

# Якты язмыш язып куйган
# Тақдирнең юмарт кулы.
# Бәхет белән тулы булсын
# Гомереңнең һәрбер елы.

# Гомер юлы - тормыш юлы...



## Эзләр

Факил туган!
Минем синдә дә 60 тулды. Мин
моңа куанам: синең һәр эшеңә
уртаклашып яшә, матур дус кала. Һәм
бүген дә шулай. Синең белән Бабурева
һәм аның гаиләсе тарафыннан балалар ку-
өлешенә ямьле кала тора. Килгәндә дә
шулай булып калуыңа телим.

Синең эзләр әле
Ямьле кала.
Синең котың аша
Һәрбер бала.

*

Факил булып язгач, Факил,
Факил булып яшәгез.
Фикерле факил булып яшә син,
Сүнәргә ярамасын.

Эшең булсын да әзәр син
Чалмаларның Факиле.
Дәрәҗәң һәм сәгадәтеңдә
Мөселманнәр әҗәле.

Ин чын теләкләр белән,

Мөхәммәтшин.
30.11.13.

## Балачак эзе

Факил! Син безнең авылдашыбыз, укучыбыз.
Гаиләсе олы тарихы булган, Теләк тавы, тәкәр-
лекле Сарьазы, эчкә матур иде кешеләре
белән дан тоткан Әлки авылыннан без синең
белән. Син гаиләсе эчендә, тыйнак, булган, Уба-
лачы гаиләдә үстең. Син нечкәлек күзгәтеп,
бик күп укый идең, белемгә омтылышың зур,
туры сүзле, үзеңчә сокландыргыч каткачып
тамашачыларның ихтирамын яулаучың.
Син данлыклы Кубә урта мәктәбен тә-
мамладың. Үз көчең, белемең, тормыш
тәҗрибәң белән гаиләгә зур уңышларга
ирештең.

Факил, синең уңышларың өчен барча
авылдашларың сөенә. Синең шигырьләрең, про-
за әсәрләреңне укып, җырларыңны тыңлап хо-
зурланабыз. Шунысы куанычлы - син балачак
эзләрен бүген дә күңелеңдә саклыйсың, һәр әсәреңнән
туган як җилләренең җылысы бөркелеп тора.
Сиңа сәламәтлек, гаилә бәхете, иҗади уңышлар
телик, барлык авылдашларың, укытучыларың
исеменнән Роза апа, Ильяс абый Низамовлар.
Мөслим, декабрь, 2013нче ел.




## Юллар... юллар...

Тормышта могҗизалы хәлләр күп. Ми-
нем өчен Факил Сафин белән дуслашу
да шундый могҗизага әверелде. Уйлап
карасаң, безнең авыллар бик ерак.
Күрше-ниндидер бер якынлыкка
юл бар. Ул минем яшьлек, ә менә
аны үзем белеп бер яшьтә иде.
Минем олугак яшьләрдә кебек тоела.
Бүгенге тугандай өчен этәтте.

Хәзер, Факил, синең белән авылдаш сүз
әйтүем килә. Мин сиңа кече булсам да,
язуы буенча да гомер бер сокландым.
Синең прозаң да, поэзияң да бүгенге
татар әдәбиятында иң югары урын били.
Син барыгыз да үз ачуга кечкен
буласы булмады. Синең кара-каршы
яңа шагыйрь үрләре яулау, Син Чаллыда,
мин Мөслимдә, әмма синең миңа
карата якын күңел, тулы бөркеп. Бу
тагын бер озак еллар татулы халкы
укучыларга дә тыңлатып килә.

Дусың Фоат Садыйков.

## Бүгенге көн - үткәннәрнең кайтавазы,
## Кемнәргәдер килә көзе,
## Кемнәрнеңдер кайта язы.



Факил абый!
Сез безнең мактанычы-
быз, горурлыгыбыз. Без
сезне язучы, шагыйрь
буларак кына түгел,
авылдашыбыз буларак
та бик яратабыз,
хөрмәт итәбез. Иҗат
җимешләрегезне
көтеп калабыз. Киләчәктә дә иҗат
чишмәләрегез саекмасын. Барысы өчен
дә рәхмәт Сезгә!


Сезгә Әлки тугызынчы бик күп сәламнәр
җибәрәбез һәм кунакка көтеп калабыз.

Гөлнара Әхмәтова Хакимова
Әлки урта мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты
укытучысы, музей җитәкчесе.

# Китапларны укыдык, рәсемнәр ясадык!












































# 60

## Язучының кем икәнен беләсең килсә, аның әсәрләрен укы















Юбилеегыз котлы булсын, яраткан язучыбыз.
Өр - яңа китапларны сездән көтеп калабыз.
Сәламәт булып бик озак әле абый, яшәгез.
Нәниләрне сөендереп безгә ашыгып килегез.





Әдәбият галиме, публицист, советтан соңгы
әвердә татар милли матбугатын оештыручы-
ларның берсе Факил Сафин 1954 елның 2 гыйн-
варында Татарстан Республикасының Мөслим
районы Әмәкәй авылында туа. Күбәк урта мәк-
тәбен тәмамлагач, армия сафларында хезмәт
итә. Казан дәүләт университетын тәмамлый.
Мөслим районы мәктәпләрендә укытучы, мәк-
тәп директоры булып эшли. 1984 елдан Чаллы
шәһәрендә яши һәм иҗат итә. Автомобильләр
җыю заводында мастер, «Таң йолдызы» газета-
сы баш мөхәррире урынбасары, «Аргамак» жур-
налында җаваплы сәркатип, «Фән һәм мәктәп»
журналының баш мөхәррире, «Мәйдан» журналының баш мөхәррире, Т...
тан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, «Рухи мирасны өйрәнү фәнн...
одик үзәге» җитәкчесе булып эшли. Бүгенге көндә ул балалар-яшүсм...
өчен нәшер ителүче «Көмеш кыңгырау» газетасының баш мөхәррире.

Зурлар өчен романнар, повестьлар, хикәяләр, шигырьләр һәм бал...
лар, поэмалар иҗат иткән, гыйльми хезмәтләр авторы Факил Сафин ...
лар әдәбиятында да актив эшли. Аның «Ак канатлы йолдызлар», «Лә...
лән Арслан» китапларын нәниләр яратып укыйлар.

Факил Сафин – филология фәннәре...
дидаты, Татарстан Язучылар берлеге һә...
тарстан Журналистлар берлеге әгъзасы...
тарстанның атказанган мәдәният хезмәт...
Гаяз Исхакый, Александр Грибоедов исем...
ге әдәби премияләр лауреаты, «Тәрҗемә ...
пы» һәм «Кояшлы иҗаты өчен» Халыкар...
ләкләр иясе.

**Факил абый! Сезгә теләгебез:**
**Сөйләр сүзләрегез – ялкын булсын.**
**Ерак юлларыгыз – якын булсын,**
**Биргән киңәшләрегез – алтын булсын.**

**Бүген бары телибез без,**
**Олы бәхет, сезгә, тазалык**
**Матур исемегез калсын матур итеп**
**Татар тарихына язарлык!**


**“Көмеш кыңграу” абыебыз!**
**Сезнең эшне өлге итеп алып,**
**Мәктәп юлын матур үтәрбез.**
**Изге уйны, изге гамәлләрне”**
**Үзебезгә маяк итәрбез!**

Башлангыч сыйныф укучылары






**«Үткәннәргә  борылып карасам мин,**
**Искә төшә мәктәп еллары.**
**Бер кайгысыз шаян дусларымны**
**Кая алып китте юллар?....»**














**“Әйләнәм дә борылып карыйм**
**Үтелгән юлларыма**
**Юллар кайтыр, кайтыр әле**
**Яшьлегем язларына.”**



# Тамырлар яшәтә безне







**“Анам теле – ул иманым,
Атам йорты – ул Ватан.
Әмәк – изге төягем,
Синдә башлап туа таң.”**











**“Йолдыз- карлар уйнап бөтерелә,
Киң кырларым төренә ак шәлгә.
Күчеп торсын жаннан жанга жылы,
Дуслык кирәк жирдә яшәргә!”**






Безнең якта - бер сер бар,
Тылсымлы безнең яклар.
Туган җирем, тик син куйдың
Җырларыма канатлар!



Авыр чакта кулга каләм алам.



Күчеп торсын җаннан җанга җылы,
Дуслык кирәк җирдә яшәргә!



Илһам килгән чакта



Музыкаль гаилә Әхмәтшиннар белән

"Яктыра донья шул чакта,
Нурга торенә җиһан:
“Бар ул кеше, яши кеше,
Ул бәхет өчен туган!”










Еллар имин, тыныч булсын!
Күнелләр күтәренке.





Гаиләм-минем таянычым! Тормыш иптәшем-Ләйсирә, кызым-Гөлнара




# Гамьле затның гына була
# Халкына әйтер сүзе.




**Бу очрашу торсын җим булып,**
**Бер алтын бөртек булып!**
**Ходай бирсен озак еллар**
**Яшәргә бөркет булып!**

**Редколлегия:** **Кәримова Ризидә 10А, Мотигуллина Эльвина 10А, Пинакова Софья 8Б, Страхова Диана 8В, Гыймазова Эвелина 8В, Рәхимова Камилә 8Б, Гарипов Айнур 8А, Хисматуллина Айзилә 8А.**

**Түгәрәк җитәкчесе - Власова Роза Дәүләтовна.**

**Газетаның электрон вариантын мәктәпнең сайтында карый аласыз:**
***http://edu.tatar.ru/n_chelny/sch4***